ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

**Шәймиев, М. Ш. «Кыйблабыз дөреслеген тормыш үзе раслады»** / М. Шәймиев // Ватаным Татарстан. – 2020. – № 74 (27 май). – Б. 3.



# Минтимер Шәймиев: «Кыйблабыз дөреслеген тормыш үзе раслады» (ЭКСКЛЮЗИВ)

— 27.05.2020 - Җәмгыять 0

Тарихның һәр чоры аерым шәхесләр эшчәнлеге белән бәйле. Татарстан тарихында Минтимер Шәймиев исеме аерым урын алып тора. Ул җитәкчелек иткән елларны еш кына «Шәймиев чоры» дип тә атыйлар. Чөнки беренче Президент җәмгыятьтәге бөтен үзгәрешләрнең үзәгендә кайнады, республика һәм милли мәсьәләләргә кагылышлы кызу бәхәсләр барганда хәлиткеч сүзне әйтте. «Ватаным Татарстан» газетасына Татарстанның беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев үзгәртеп кору чоры, милләтара дуслык, республика һәм туган тел язмышы турында сөйләде.